Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Оет торак пунктында **халык җыены нәтиҗәләре турында** КАРАР

27.11.2024 № 2

06.10.2003 ел. № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел 16нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, "2025нче елда Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Оет авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны сарыф итүнең конкрет юнәлешләренә юнәлдерү:

1) "Торак пункт (Оет авылы авылы) чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту" белән килешәсезме"

дигән сорау буенча 2024 нче елның 27нче ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия 153 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 77 кеше кертелгән. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 77 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе ечен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде. Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Шыңар авыл җирлегенең Оет авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. "2025нче елда Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Оет авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны сарыф итүнең түбәндәге конкрет юнәлешләренә юнәлдерү: 1) Торак пункт (Оет авылы) чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту" турында карарны кабул ителгән дип санарга;

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов